КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** | **КАРАР**

2020 ел, 24 июль | г.Казань | № 620

Татарстан Республикасының эвакуация
комиссиясен төзү турында

«Гражданнар оборонасы турында» 1998 елның 12 февралендәге 28-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү тәртибе турында» 2004 елның 22 июнендәге 303 номерлы, «Россия Федерациясендә гражданнар оборонасы турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2007 елның 26 ноябрендәге 804 номерлы карарлары, «Татарстан Республикасында граждан оборонасы турында» 2020 елның 13 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында гражданнар оборонасын оештыру һәм алып бару турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 елның 22 ноябрендәге ПУ-598 номерлы Татарстан Республикасы Президенты Указы нигезендә һәм халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләүне планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү эшен оештыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасының эвакуация комиссиясен төзергә.
2. Түбәндәгеләрне расларга:
Татарстан Республикасының эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне;
Татарстан Республикасының эвакуация комиссиясе составын.
3. Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре башлыкларына, Татарстан Республикасы оешмалары җитәкчеләренә тиешле эвакуация органнарын төзүне тәкъдим итәргә.
4. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына Татарстан Республикасы халкын, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне имин районнарга эвакуацияләү чараларын планлаштыру белән оештыру-методик яктан җитәкчелек итүне тәэмин итәргә.
5. Түбәндәгеләрне үз көчен югалткан дип танырга:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарын;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 8 май, 299 нчы карарын;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 29 февраль, 169 нчы карарын;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 6 март, 148 нче карарын;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карары белән расланган Республика эвакуация комиссиясе составына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 29 февраль, 122 нче карарын;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карары белән расланган Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 16 июнь, 409 нчы карарын;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карары белән расланган Республика эвакуация комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 7 февраль, 63 нче карарын;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Республика эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмәне һәм аның составын раслау турында» 2006 ел, 26 июнь, 323 нче карары белән расланган Республика эвакуация комиссиясе составына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2019 ел, 5 февраль, 68 нчы карарын.

6. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 24 июль, 620 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының эвакуация комиссиясе турында
нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Бу Татарстан Республикасының эвакуация комиссиясе турындагы нигезләмә (алга таба – Нигезләмә) Татарстан Республикасының эвакуация комиссиясе (алга таба – Комиссия) статусын һәм эшчәнлеге тәртибен билгели.

1.2. Комиссия Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнары, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм оешмаларның тыныч вакытта, гражданнар оборонасы системасын билгеләнгән әзерлек дәрәҗәсенә күчергәндә һәм хәрби вакытта эвакуация чараларын турыдан-туры планлаштыру, әзерләү һәм үткәрү буенча гамәлләрен килештерүне тәэмин итә торган даими эшләүче координацияләү органы булып тора.

1.3. Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты указларына, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм боерыкларына, Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар салган зыяннарны бетерү министрлыгының норматив хокукый актларына, Татарстан Республикасы Конституциясенә, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Президенты указларына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм боерыкларына, шулай ук бу Нигезләмәгә таянып эш итә.

1.4. Комиссия Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы җитәкчесенә – Татарстан Республикасы Президентына (алга таба – Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы җитәкчесе) һәм Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы җитәкчесе урынбасарына – Татарстан Республикасы Премьер-министрына (алга таба – Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы җитәкчесе урынбасарына) буйсына һәм Татарстан Республикасында эвакуация чаралары белән идарә итү органы булып тора.

1.5. Комиссия составы Татарстан Республикасы министрлыкларының җитәкчелек составы арасыннан, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары һәм Татарстан Республикасы Хәрби комиссариаты вәкилләреннән төзелә.

1.6. Комиссия составына түбәндәгеләр керә:

комиссия рәисе;

комиссия рәисе урынбасарлары;

комиссия секретаре;

комиссия әгъзалары.

Комиссиянең персональ составы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

1.7. Комиссия составында түбәндәге төркемнәр оештырыла:

хәбәр итү һәм элемтә;

эвакуацияләнә торган халыкны һәм мәгълүматны исәпкә алу;

имин районнарда эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыруны оештыру;

эвакуацияләнә торган халыкның беренчел тормыш эшчәнлеген тәэмин итү;

юл һәм транспорт белән тәэмин итү;

матди кыйммәтләрне эвакуацияләүне исәпкә алу;

мәдәни кыйммәтләрне эвакуацияләүне исәпкә алу.

Комиссия Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан оешмалар вәкилләреннән торган эшче төркемнәр составын формалаштыра. Эшче төркемнәр җитәкчеләре булып Комиссия әгъзалары тора.

Эшче төркемнәрнең персональ составы Комиссия рәисе тарафыннан раслана.

Эшче төркемнәрнең эш тәртибе һәм планнары аларның җитәкчеләре тарафыннан Комиссиянең эш планы нигезендә раслана.

1.8. Комиссия эше гражданнар оборонасының көндәлек эшчәнлеге режимында бер елга эш планы нигезендә оештырыла һәм үткәрелә.

Эвакуация чараларын планлаштыру, аларны һәрьяклап тәэмин итү, Татарстан Республикасы эвакуация органнарының әзерлек торышын һәм әзерлеген тикшерүдә тоту мәсьәләләрен карап тикшерү өчен кимендә ярты елга бер тапкыр Комиссия утырышлары үткәрелә.

1.9. Комиссия һәм аның эшче төркемнәре әгъзалары тыныч һәм сугыш вакытында эвакуация чараларын үткәрүгә бәйле Комиссия эшчәнлеге чорында, шулай ук Комиссиянең бер елга эш планы нигезендә дәресләр, өйрәнүләр, күнекмәләр үткәрү чорында төп эш урыны буенча вазыйфаларны башкарудан азат ителә.

1.10. Комиссия үз эшчәнлеген Казан шәһәре, Коләхмәтов урамы, 5 нче А йорт адресы буенча урнашкан Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методик үзәге бинасында урнаша торган Комиссия идарәсе пунктыннан гамәлгә ашыра.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары һәм функцияләре

2.1. Комиссиянең төп бурычлары түбәндәгеләр була:

эвакуация планнарын эшләүне һәм аларга төзәтмәләр кертүне оештыру;

эвакуация органнарын үз вакытында комплектлауны, аларның сыйфатлы әзерлеген тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру;

эвакуация чараларын әзерләүне һәм үткәрүне тикшерүдә тотуны оештыру һәм гамәлгә ашыру.

2.2. Үзенә йөкләнгән бурычларны тормышка ашыру өчен Комиссия түбәндәге функцияләрне башкара:

а) тыныч вакытта:

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының эвакуация комиссияләре һәм эвакуацияләнгән халыкны кабул итү комиссияләре, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары һәм оешмалар белән берлектә, Татарстан Республикасының халыкны, матди һәм мәдәни кыйммәтләрне эвакуацияләү һәм таратып урнаштыру планын (алга таба – эвакуация планы) эшләүне һәм ел саен төгәлләштерүне оештыру;

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары һәм Татарстан Республикасы оешмалары, коткару хезмәтләре белән берлектә, эвакуация чараларын һәм имин районда эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыруга әзерләү чараларын һәрьяклап тәэмин итү планнарын эшләүне оештыру, бу чараларның үтәлешен тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру;

эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү мәсьәләләре буенча хәрби идарә органнары белән хезмәттәшлекне оештыру;

эвакуациянең эшләнә торган планнарын һәм эвакуация органнарының аларны үтәүгә әзерлеген тикшерү максатларында гражданнар оборонасы укуларында катнашу;

эвакуация чараларын планлаштыру һәм үткәрү мәсьәләләре буенча эвакуация һәм эвакуацияләнгән халыкны кабул итү комиссияләре белән үзара хезмәттәшлек итү;

б) гражданнар оборонасы буенча чараларны үтәгәндә:

эвакуацияне тәэмин итү, хәбәр итү һәм элемтә схемаларын ачыклау өчен эвакуация органнары, көчләре һәм чараларының әзер булуын тәэмин итү;

эвакуацияләнә торган халык категорияләрен һәм санын ачыклау;

Татарстан Республикасының эвакуация органнарында эвакуация планын ачыклау һәм бу эшне башкаруны тикшерүдә тотуны гамәлгә ашыру;

җыелма эвакуация пунктларын җәелдерүгә әзерлекне оештыру, аларны җәелдерү барышын тикшерүдә тоту;

халыкны, халыкны утырту һәм чыгару пунктларын һәм арадаш эвакуация пунктларын эвакуацияләүгә әзерләү;

транспорт чараларын кешеләрне эвакуацияләү өчен йөртүләргә әзерләү;

транспорт оешмалары белән берлектә, халыкны мөмкин булган куркыныч зоналардан, шулай ук арадаш эвакуацияләү пунктларыннан имин районнардагы халыкны урнаштыру пунктларына чыгару өчен бүлеп бирелә торган барлык транспорт төрләрен куллану тәртибен ачыклау;

җыелма эвакуация пунктлары, халыкны утырту пунктлары урнашу районнарында булган саклык корылмаларының әзер булуын оештыру;

буйсынудагы һәм үзара хезмәттәшлек итүче эвакуация һәм эвакуацияләнгән халыкны кабул итү комиссияләре белән имин районнарда халыкны кабул итү, урнаштыру һәм беренчел тормыш эшчәнлеген тәэмин итү планнарын ачыклау;

в) эвакуация үткәрү турында күрсәтмә игълан итү белән:

буйсынудагы эвакуация органнары һәм транспорт хезмәтләре белән элемтә саклау, халыкка хәбәр итүне һәм утырту пунктларына бару өчен транспорт бирүне оештыру;

халыкны эвакуацияләү планнарын үтәүне оештыру;

буйсынудагы эвакуация комиссияләренең эвакуацияләнә торган халыкка хәбәр итү, аны җыю һәм имин районнарга җибәрү эше белән җитәкчелек итү;

эвакуация барышында хәрәкәтне җайга салуны оештыру һәм тәртипне саклау;

чыгарыла торган халык саны турында эвакуацияләнгән халыкны кабул итү комиссияләренә хәбәр итү;

халыкны эвакуацияләү барышы турындагы мәгълүматларны җыю һәм гомумиләштерү, Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы җитәкчесенә һәм аның урынбасарына докладлар бирү;

эвакуация чараларын оештыру, тәэмин итү һәм үткәрү мәсьәләләре буенча хәрби идарә органнары һәм тиешле коткару хезмәтләре (хәрби вакытта) белән үзара хезмәттәшлекне оештыру;

имин районнарда халыкның беренчел тормыш эшчәнлеген тәэмин итүне һәм аны саклауны оештыру.

## 3. Комиссиянең хокуклары

3.1. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнарыннан Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр буенча материалларны һәм мәгълүматны билгеләнгән тәртиптә соратып алырга;

кирәк булганда, үз утырышларына Комиссия компетенциясенә караган мәсьәләләр

буенча Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, муниципаль берәмлекләр һәм теләсә кайсы милек рәвешендәге оешмалар вәкилләрен билгеләнгән тәртиптә чакырырга һәм тиешле карарлар кабул итәргә.

3.2. Комиссия карарлары утырышта катнашучы Комиссия әгъзаларының гади күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм Комиссия рәисе һәм секретаре имзасын куя торган беркетмә белән рәсмиләштерелә. Кирәк булганда, Комиссия карары нигезендә Татарстан Республикасының гражданнар оборонасы җитәкчесе һәм аның урынбасары боерыклары һәм күрсәтмәләре чыгарыла.

## 4. Комиссия әгъзаларының хокуклары

Комиссия әгъзасы түбәндәгеләргә хокуклы:

Комиссия каравына кертелә торган мәсьәләләрне әзерләүдә катнашырга;

Комиссия рәисеннән һәм секретареннән аның эшчәнлегенә караган мәсьәләләр буенча мәгълүмат алырга.

## 5. Комиссия әгъзаларын махсус әзерләүне оештыру

Комиссия әгъзаларын әзерләү түбәндәгеләрдә оештырыла һәм үткәрелә:

Татарстан Республикасының Гражданнар оборонасы һәм гадәттән тыш хәлләр буенча укыту-методик үзәгендә;

укыту һәм укыту-методик җыеннарында;

план буенча махсус дәресләрдә;

өйрәнүләр һәм күнекмәләр ясау барышында.

## 6. Комиссия эшче төркемнәренең оештыру структурасы

6.1. Эшче төркемнәр һәм бүлекләр структурасы, составы һәм аларны формалаштыру өчен җаваплы органнар:

а) хәбәр итү һәм элемтә төркеме (биш кеше) Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан төзелә.

Төркем түбәндәгеләрне үз эченә ала:

элемтә бүлеген – «Таттелеком» гавами акционерлык җәмгыятеннән ике кеше (килешү буенча);

хәбәр итү бүлеген – өч кеше, шул исәптән «Татарстан» дәүләт телевизион һәм радиотапшырулар компаниясенең «Бөтенроссия дәүләт телевизион һәм радиотапшырулар компаниясе» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалыннан – ике кеше (килешү буенча), Татарстан Республикасының Радиотелевизион тапшыру үзәгеннән – «Россия телевидение һәм радиотапшырулар челтәре» федераль дәүләт унитар предприятиесе филиалыннан – бер кеше (килешү буенча);

б) эвакуацияләнә торган халыкны һәм мәгълүматны исәпкә алу төркеме (биш кеше) Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы тарафыннан төзелә. Шул исәптән:

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгыннан – өч кеше;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан – ике кеше;

в) эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыруны оештыру төркеме (биш кеше) Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы тарафыннан төзелә. Шул исәптән:

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгыннан – өч кеше;

Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан – ике кеше;

г) эвакуацияләнә торган халыкның беренчел тормыш эшчәнлеген тәэмин итү төркеме (10 кеше) Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы тарафыннан төзелә.

Төркем түбәндәгеләрне үз эченә ала:

азык-төлек һәм беренчел кирәк-яраклар белән тәэмин итү бүлеген –ике кеше, шул исәптән Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгыннан – бер кеше, Татарстан Республикасының Кулланучылар кооперациясе оешмалары берлегеннән (алга таба – Татарстан Кулланучылар берлеге) – бер кеше;

инженерлык һәм коммуналь-техник тәэмин итү бүлеген – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгыннан ике кеше;

медицина белән тәэмин итү бүлеген – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгыннан ике кеше;

ягулык-майлау материаллары белән тәэмин итү бүлеген – «ТАИФ-НК АЗС» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятеннән ике кеше;

җәмәгать тәртибен саклау һәм хәрәкәт иминлеген тәэмин итү бүлеген – Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгыннан ике кеше (килешү буенча);

д) юл һәм транспорт белән тәэмин итү төркеме (10 кеше) тулы составта Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан төзелә.

Төркем түбәндәгеләрне үз эченә ала:

елга буйлап йөртүләр бүлеген – ике кеше;

тимер юл транспорты бүлеген – өч кеше;

автомобильләр белән йөртүләр һәм шәһәр электр транспорты бүлеген – өч кеше;

юл бүлеген – ике кеше;

е) матди кыйммәтләрне эвакуацияләүне исәпкә алу төркеме (дүрт кеше) Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгы тарафыннан төзелә. Шул исәптән:

Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгыннан – бер кеше;

Татарстан Кулланучылар берлегеннән – бер кеше;

Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгыннан – бер кеше;

Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгыннан – бер кеше;

ж) мәдәни кыйммәтләрне эвакуацияләүне исәпкә алу төркеме (өч кеше) тулы составта Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы тарафыннан төзелә.

6.2. Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгы тарафыннан, Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнары һәм Комиссия эшен тәэмин итү өчен төркемнәр төзүче оешмалар белән берлектә, түбәндәге документлар эшләнә:

Татарстан Республикасы халкын, матди һәм мәдәни кыйммәтләрен эвакуацияләү һәм таратып урнаштыру планы;

Комиссия әгъзаларының функциональ бурычлары;

Комиссия әгъзаларының эш документлары;

белешмә документлар һәм материаллар.

Комиссия һәм аның эшче төркемнәр әгъзаларының эш һәм белешмә документлары һәм материаллары исемлеге Комиссия рәисе тарафыннан билгеләнә.

## 7. Йомгаклау нигезләмәләре

Комиссия Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән бетерелә.

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2020 ел, 24 июль, 620 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасының эвакуация комиссиясе
составы

| | |
|---|---|
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры, комиссия рәисе |
| Степущенко Олег Александрович | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары, комиссия рәисенең  гражданнар оборонасы мәсьәләләре буенча урынбасары |
| Суржко Николай Владимирович | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры урынбасары, комиссия рәисенең табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрне бетерү мәсьәләләре буенча урынбасары |
| Родионов Павел Геннадьевич | Татарстан Республикасы Гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министрлыгының гражданнар оборонасы өлкәсендә вәкаләтләрне тормышка ашыру бүлеге башлыгы, комиссия секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Авандеев Алексей Юрьевич | Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгының элемтә хезмәтләрен үстерү бүлеге башлыгы – хәбәр итү һәм элемтә төркеме башлыгы |
| Борһанов Эльс Ленсович | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының оештыру эшләре һәм социаль үсеш бүлеге башлыгы – имин районнарда эвакуацияләнә торган халыкны урнаштыру төркеме башлыгы |
| Исхаков Фәнис Авгатович | Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының метрологик һәм техник тикшерүдә тоту, хезмәтне саклау идарәсе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Минһаҗева Гүзәл Ринат кызы | Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгының контроль һәм эш башкару бүлеге башлыгы – мәдәни кыйммәтләрне эвакуацияләүне исәпкә алу төркеме башлыгы |
| Мөхәммәтҗанов Фәргать Госман улы | Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының полиция башлыгы (җәмәгать тәртибен саклау буенча) урынбасары (килешү буенча) |
| Салихов Илдар Низаметдин улы | Татарстан Республикасы Хәрби комиссариатының оператив-план бүлеге башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча) |
| Сиражетдинова Людмила Владимировна | Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгының архитектура бүлеге башлыгы – эвакуацияләнә торган халыкның беренчел тормыш эшчәнлеген тәэмин итү төркеме башлыгы |
| Сидоров Алексей Васильевич | Татарстан Республикасы Транспорт һәм юл хуҗалыгы министрлыгының транспорт идарәсе башлыгы – юл һәм транспорт белән тәэмин итү төркеме башлыгы |
| Сурдаков Андрей Алексеевич | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының эшләр идарәчесе |
| Хисаметдинова Гүзәл Тәлгать кызы | Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының урман эшкәртү һәм җиңел сәнәгать бүлеге башлыгы – матди байлыкларны эвакуацияләүне исәпкә алу төркеме башлыгы |
| Хисмәтуллина Ралинә Рүзәл кызы | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының җир, мөлкәт мөнәсәбәтләре һәм матди-техник тәэмин итү бүлеге башлыгы – эвакуацияләнә торган халыкны һәм мәгълүматны исәпкә алу төркеме башлыгы. |